СОВЕТ НИКИФОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Карла Маркса, д.3, с. Никифорово, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422166

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НИКИФОРОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Карл Маркс ур., 3 нче йорт, Никифорово авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422166

тел.(факс): (85563) 2-42-38; e-mail: Nikifor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

КАРАР                                                                 РЕШЕНИЕ

№1-34                                                  17 сентябрь 2018 ел

## “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авылы җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 ел, 06 октябрь, 131 -ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы, “ Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 ел, 28 июль, 45 ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 нче статьясы , “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авылы җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 87, 88,89 нчы статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге Советы
к а р а р к а б у л и т т е:

1. Татарстан Республикасы Мамадышмуниципальрайоны Никифорово авыл Советының 2018 ел, 18 нче июнь, №1-32 санлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве алу өчен җибәрергә.
3.Дәүләт теркәве узганнан соң, әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 89 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Никифорово авыл җирлеге башлыгы Степанов С.Н. йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Никифорво авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Степанов С.Н.